| УКАЗ<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>УКАЗЫ |
|---|---|---|

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы, 2014 елның 17 ноябрендәге ПУ-1052 номерлы һәм 2015 елның 25 мартындагы ПУ-367 номерлы, 2015 елның 17 июнендәге ПУ-562 номерлы һәм 2015 елның 26 июнендәге ПУ-602 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 15 пункттагы «149», «141» һәм «39» саннарын тиешенчә «148», «140» һәм «33» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

үзенең актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 29 июль
№ ПУ-680